| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>КРЫНДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КЫРЫНДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**10.05. 2023** **№ 18**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге Башкарма комитетының «2023 елга вафат булганнарны җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясен раслау турында» 24.01.2023 елның 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР КАБУЛ ИТӘ:

1. «2023 елга вафат булганнарны күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясен раслау турында» 24.01.2023 елның 2 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлегендә 2023 елга җирләү бурычын үз өстенә алган үлгәннәрне, тормыш иптәше, якын туганнары, башка туганнары, законлы вәкиле яки башка затларны җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе (1 нче кушымта)»;

2) 1 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлегендә 2023 елга җирләү бурычын үз өстенә алган үлгәннәрне, тормыш иптәше, якын туганнары, башка туганнары, законлы вәкиле яки башка затларны җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе (2 нче кушымта)»;

3) Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге Башкарма комитетының 24.01.2023 елның 2 номерлы "2023 елга үлгәннәрне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясен раслау турында" карарына 1 нче кушымтаның атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлегендә 2023 елга җирләү бурычын үз өстенә алган үлгәннәрне, тормыш иптәше, якын туганнары, башка туганнары, законлы вәкиле яки башка затларны җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе»;

4) Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге Башкарма комитетының 24.01.2023 елның 2 номерлы "2023 елга үлгәннәрне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясен раслау турында" карарына 2 нче кушымтаның атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлегендә 2023 елга җирләү бурычын үз өстенә алган үлгәннәрне, тормыш иптәше, якын туганнары, башка туганнары булмаган, законлы вәкиле яки башка затларны җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендында игълан итәргә, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районының Кырынды
авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе А. А. Нәфыйков